Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Югары Мактама авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел №2

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлеге Югары Мактама авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 16 ноябрендә, 11 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлегенең Югары Мактама авылында Октябрь, М.Жәлил урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2019 елның 16 ноябрендә, 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлегенең Югары Мактама авылында Крупская, Сәйдәш, Тукай, Чапай, С.Галиев, С.Хаким, С.Гатауллин¸ Гафиатуллин, Сөләйман, И.Рахимов урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Югары Мактама авыл җирлегенең Югары Мактама авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: торак пунктны су белән тәэмин итүне норматив хәлгә китерү, сметалар тезү һәм техник күзәтчелек үткәрү ечен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Халык җыены этапларын Югары Мактама авыл клубы бинасында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Югары Мактама авылы, Октябрь урамы, 71 йортта уздырырга.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлегенең Югары Мактама авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

6. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Югары Мактама авылы, Октябрь урамы, 71 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында»

(PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Югары Мактама
авыл җирлеге башлыгы Н.Т. Нуриев